**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.03.2017 Балык Бистәсе штп. № 41пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 21.01.2014 №07пи карары белән расланган Балык Бистәсе муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналар түләвен формалаштыру һәм аның өчен түләү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 65 статьясындагы 2 өлеше, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының 2014 елның 21 гыйнварындагы 07пи номерлы карары белән расланган Балык Бистәсе муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны карап торган һәм караган өчен ата-ана түләвен формалаштыру һәм алу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 2.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле өченче абзац өстәргә:

«Ике һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балалары булган һәм даими керем булмау сәбәпле ата-ана түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсацияләр алу мөмкинлеге булмаган ялгыз аналар өчен ата-аналар түләве күләме югарыда күрсәтелгән чыгымнар күләменең 50 процентын тәшкил итә. Шул ук вакытта ялгыз ана категориясе буенча ташламага хокук бирә торган бала мәктәпкәчә белем бирү оешмасына йөрергә тиеш.»

1.2) түбәндәге эчтәлекле 2.3.1 пункт өстәргә:

«2.3.1.Ата-ана түләвен кертүдән азат итү хокукын яисә ата-ана түләвен киметүгә хокукны әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында күрсәтелгән чыгымнар

күләменең 50 проценты күләмендә раслау өчен, ата-аналар (законлы вәкилләр) мәктәпкәчә белем бирү оешмасына түбәндәге документларны тапшыралар:

- ташламалар бирү турында мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесе исеменә язмача гариза;

гаилә составы турында белешмә;

-һәр бала туу турында таныклыкның күчермәсен.

Күрсәтелгән документлардан тыш, гражданнарның аерым категорияләре өстәмә рәвештә түбәндәге документларны тапшыралар:

- опекуннар, тәрбиягә бала алган ата-аналар - бала алу, опекун билгеләү турында хокукый акт күчермәсен;

- инвалид баланың ата-анасы - баланың инвалидлыгын билгеләү фактын раслый торган белешмәнең күчермәсе;

-туберкулез интоксикациясе булган балаларның ата-аналары - профильле табибның медицина белешмәсе күчермәләре;

- ата-ана (законлы вәкилләр), өч һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче - күпбалалы гаилә таныклыгы күчермәсен;

-ике һәм аннан да күбрәк баласы булган ялгыз аналар – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 31.10.1998 ел, №1274 карары белән расланган 25 нче форма буенча туу турында белешмә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балык Бистәсе муниципаль районындагы социаль яклау бүлегеннән белешмә, ул ата-ана түләвенең өстәмә компенсация алмау фактын раслый.

Күрсәтелгән ташламаларны алу хокукы ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) документлар белән гариза тапшырган айдан алып агымдагы айның 20 числосына кадәр (шул исәптән кертеп) тапшырылган очракта барлыкка килә. Агымдагы айның 20 числосыннан соң гариза биргәндә, ташлама киләсе айдан бирелә.

Ата-аналар (законлы вәкилләр) тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплы. Ташлама бирелгәннән соң алдагы айларда ата-аналар түләве өлешенә өстәмә компенсация билгеләгән очракта, ата-аналар (законлы вәкилләр) бу хакта мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенә хәбәр итәргә тиеш.

Ташламалар бирү турында гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан алар мәктәпкәчә белем бирү оешмасына кергән көннән алып 3 эш көне эчендә карала. Карап тикшерү нәтиҗәләре буенча мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан ташлама бирү яки бирүдән баш тарту турында карар кабул ителә.

Әлеге Тәртипнең 2.2-2.3. пунктларында каралган ташламалар бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

-Әлеге Тәртипнең 2.3.1 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган исемлеген тапшыру;

- тапшырылган документлардагы мәгълүматларның дөрес булмавы.

Ата-аналарга (законлы вәкилләргә) кабул ителгән карар турында 3 эш көне эчендә хәбәр ителә.

Берничә нигез буенча ташламага хокукы булган ата-аналарга (законлы вәкилләргә) ташлама алар сайлаган нигезләрнең берсе буенча билгеләнә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Д.Ә.Низамов